| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» апрель 2021 ел г. Альметьевск № 530

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балигъ булмаган зат карамагындагы күчемсез мөлкәтне читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 23 гыйнварындагы 59 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2021 елның 25 мартындагы 02-08-01/127 номерлы протестын карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балигъ булмаган зат карамагындагы күчемсез мөлкәтне читләштерү буенча килешүне гамәлгә ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 23 гыйнварындагы 59 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 мартындагы 434 номерлы, 2020 елның 29 июнендәге 858 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.5. Хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге» | 1) ата-аналарның (икесенең дә) яисә аларны алмаштыручы затларның алыш-бирешне башкаруны рөхсәт итү турындагы үтенече белән гаризасы (мөрәҗәгать итүче);<br>2) законлы вәкилләрнең язма ризалыгы белән эш итүче 14-ундүрт яшькә җиткән балигъ булмаган затның гаризасы (Регламентка 1 нче кушымта); | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | 3) ата-аналарның яисә аларны алмаштыручы затларның паспортлары күчермәләре;<br>4) сатыла торган һәм яңа сатып алына торган күчемсез мөлкәткә техник паспортларның күчермәләрен (яисә БТИ белешмәсен);<br>5) сатыла торган һәм сатып алына торган күчемсез милек объектына хокук билгели торган документларның күчермәләрен;<br>6) ана капиталы акчаларын җәлеп итеп торак сатып алынган очракта:<br>- ана капиталына сертификат күчермәсе;<br>- ана капиталын индексацияләү турында белешмә.<br>7) сатып алына торган күчемсез мөлкәт объекты милекчеләре гаризасы-ризалыгы;<br>8) балигъ булмаган зат исеменә банкта счет;<br>9) торак урын сатып алганда, кредит акчаларыннан файдаланып, күчемсез мөлкәт сатып алуга кредит бирә торган учреждениедән хәбәрнамә бирергә кирәк;<br>10) нотариаль яктан расланган йөкләмә.<br>Документларның күчермәләре оригиналлар булганда 1 нөсхәдә бирелә; документларның нотариаль таныкланган күчермәләрен кабул итү мөмкин. | |

2 бүлекнең 2.6. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында килеп чыга:<br>- балигъ булмаганны | |

| | | |
|---|---|---|
| булган хезмәтләр күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге» | теркәү урыны буенча йорт китабыннан өземтә, ул килешүгә рөхсәт бирелә торган муниципаль районнан булуын раслый;<br>- торак мәйданының йорт китабыннан шәхси финанс счетлары һәм торак биналарны сатып алу (алмаштыру) урыныннан аерым-аерым йорт китабыннан өземтәләр;<br>- сатыла торган һәм сатып алына торган күчемсез мөлкәткә хокук билгели торган документлар.<br>- бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе (шул исәптән 14 яшьтән өлкәнрәк);<br>Күрсәтелгән документларны мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.». | |

Карарга 4 нче кушымтада:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Ф.И.О. | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Шамсуллина Маргарита Николаевна | «Опека» идарәсе башлыгы | 32-90-74 | opeka-almet@mail.ru |

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы — А.Н. Подовалов